КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь г.Казань № 1313

2022 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында

2022 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планын (алга таба – План) расларга.

2. Планны тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертергә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Планны тормышка ашыруда катнашучы башкарма хакимият федераль органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына:

2022 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыру буенча чаралар күрергә;

хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр План чараларын тормышка ашыру барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрүне.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган икенче айның 10 ысына кадәр, җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин